**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 31 май № 364

г. Казань

Татарстан Республикасы милкендә булган социаль кулланылыштагы торак урыннарны наемга бирү шартнамәләре буенча наемга бирүче булырга вәкаләтле оешманың әлеге шартнамәләрне төзүгә һәм үтәүгә карата Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 7 пунктча нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы милкендә булган социаль кулланылыштагы торак урыннарны наемга бирү шартнамәләре буенча наемга бирүче булырга вәкаләтле оешманың әлеге шартнамәләрне төзүгә һәм үтәүгә карата Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы милкендә булган социаль кулланылыштагы торак урыннарны наемга бирү шартнамәләре буенча наемга бирүче булырга вәкаләтле оешманың әлеге шартнамәләрне төзүгә һәм үтәүгә карата Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган вазыйфаларын Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 31 май, 364 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы милкендә булган социаль кулланылыштагы торак урыннарны наемга бирү шартнамәләре буенча наемга бирүче булырга вәкаләтле оешманың әлеге шартнамәләрне төзүгә һәм үтәүгә карата Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Торак кодексының $91^2$ статьясындагы 4 өлеш, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 7 пунктча нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы милкендә булган социаль кулланылыштагы торак урыннарны наемга бирү шартнамәләре буенча наемга бирүче булырга вәкаләтле оешманың әлеге шартнамәләрне төзүгә һәм үтәүгә карата Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыру процедурасын билгели.

2. Әлеге Тәртиптә файдаланыла торган төп терминнар һәм төшенчәләр:

социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемга бирүче – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнары яисә мондый органнар вәкаләтләр биргән (төзегән) оешмалар (алга таба – наемга бирүче);

тикшерү – Татарстан Республикасы милкендә булган социаль кулланылыштагы торак урыннарны наемга бирү шартнамәләре буенча наемга бирүченең әлеге шартнамәләрне төзүгә һәм үтәүгә карата Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәвен тикшерү буенча Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) үткәрә торган чаралар җыелмасы;

тикшерү акты – тикшерү нәтиҗәләре буенча ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының вазыйфаи затлары төзи торган документ.

3. Татарстан Республикасы милкендә булган социаль кулланылыштагы торак урыннарны наемга бирү шартнамәләре буенча наемга бирүченең әлеге шартнамәләрне төзүгә һәм үтәүгә карата Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәвен тикшерү ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан тикшерүләр үткәрү, наемга бирүчедән законнарда каралган мәгълүматлар алу, социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемга бирү шартнамәләре (алга таба – наем шартнамәсе) буенча торак урыннар бирү турында гражданнардан кергән гаризаларның саны турында мәгълүматны, төзелгән шатнамәләрне дә кертеп, наем шартнамәсе нигезендә барлыкка килгән торак урынга милек хокукына чикләүләрне (өстәп бирүләрне) дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматны алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

4. Тикшерү теләсә кайсы вакыт аралыгында һәм еллык планлы тикшерүләр үткәрү планын төземичә башкарыла. Тикшерүләр үткәрү вакыты чикләнмәгән. Наемга бирүчене планнан тыш тикшерүләр прокуратура органнары белән килештермичә һәм наемга бирүчегә мондый тикшерүләр үткәреләчәге турында алдан хәбәр итмичә үткәрелә.

5. Тикшерү Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры яки аның урынбасарының тикшерү үткәрү турында боерыгы нигезендә үткәрелә. Тикшерү тикшерү үткәрү турында боерыкта күрсәтелгән зат яки затлар тарафыннан гына үткәрелә ала.

6. Документларны тикшергәндә ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы наемга бирүчегә документларны тикшерү өчен кирәк булган документларны күрсәтелгән вакытта тапшыру турында сорату җибәрә. Наемга бирүче соратуда күрсәтелгән вакытта ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына соратуда күрсәтелгән документларны тапшыра. Документлар наемга бирүче мөһере (булганда) һәм имзасы белән таныкланган күчермәләр рәвешендә тапшырыла.

7. Әгәр документларны тикшергәндә түбәндәгеләр мөмкин булмаса, урынга чыгып тикшерүләр үткәрелә:

наемга бирүченең ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карамагында булган документларындагы мәгълүматларның тулы һәм дөрес булуына ышану;

наемга бирүче эшчәнлегенең законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килүен урынга чыгып тикшерү буенча чара үткәрмичә бәяләү.

8. Урынга чыгып тикшерү үткәргәндә наемга бирүче тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларга кирәкле оештыру һәм техник ярдәм күрсәтергә, шул исәптән аларны кирәкле бүлмәләр, оештыру техникасы, канцелярия кирәк-яраклары һәм тикшерү үткәрү өчен кирәкле башка чаралар белән тәэмин итәргә тиеш.

9. Тикшерүләр үткәрүгә нигезсез каршы торучы, тикшерүләр үткәрүдән качарга тырышкан һәм (яки) билгеле булган законнар бозуларны бетерү турында ТР Җир һәм мөлкәт министрлыгының вазыйфаи затлары күрсәтмәләрен билгеләнгән вакытта үтәмәгән наемга бирүче, наемга бирүченең җитәкчесе, наемга бирүченең бүтән вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тоталар.

10. Тикшерү нәтиҗәләре буенча ТР Җир һәм мөлкәт министрлыгының тикшерү үткәрә торган вазыйфаи затлары тикшерү тәмамланган көннән соң биш көн эчендә тикшерү акты төзи.

11. Тикшерү акты тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе кушымталары күчермәләре белән, тикшерү акты белән танышу турында яисә танышудан баш тарту турында кәгазьгә имза куелып, наемга бирүченең җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә тапшырыла.

Наемга бирүченең җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышу турында кәгазьгә имза куюдан баш тарткан яисә тикшерү акты белән танышудан

баш тарткан очракта акт тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат белән җибәрелә, ул тикшерү актының ТР Җир һәм мөлкәт министрлыгында саклана торган нөсхәсенә теркәлә.

12. Наемга бирүченең законнар таләпләрен бозуын тикшерү үткәргәндә ТР Җир һәм мөлкәт министрлыгының тикшерү үткәргән вазыйфаи затлары тикшерү тәмамланган көннән соң биш көн эчендә Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләр кысаларында түбәндәгеләргә бурычлы:

билгеләнгән таләпләрне бозу туктатылу, билгеле булган бозулар бетерелү, билгеләнгән таләпләрне саклауны тәэмин итү буенча чаралар үткәрелү турында язмача күрсәтмә бирергә;

билгеле булган бозулар бетерү, аларны кисәтү буенча чаралар, шулай ук билгеле булган бозуларны җибәргән затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә.

13. Наемга бирүче тикшерү актында язылган фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр, яисә бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта тикшерү актын алган көннән соң 15 көн эчендә ТР Җир һәм мөлкәт министрлыгына язма рәвештә тикшерү актына карата һәм (яки) бирелгән күрсәтмәгә карата гомумән яки аның аерым нигезләмәләренә карата кире кагу тапшырырга хокуклы. Бу чакта наемга бирүче мондый кире кагуларга аларның нигезле булуын раслый торган документларны (документларның таныкланган күчермәләрен) теркәргә яисә килешенгән вакытта аларны ТР Җир һәм мөлкәт министрлыгына тапшырырга хокуклы.

14. Наемга бирүче тикшерү акты һәм (яки) күрсәтмә белән килешмәгән очракта әлеге документларга аның тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

15. Тикшерү барышында административ хокук бозулар яки җинаять җаваплылыгына тартыла торган гамәл билгеләре булган шартлар килеп чыккан очракта тикшерү акты ТР Җир һәм мөлкәт министрлыгы тарафыннан компетенцияләренә туры китереп, законнарда билгеләнгән вакытта хокук саклау органнарына җибәрелә.

___________________________